| | | |
|---|---|---|
| Республика Татарстан<br>САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | Татарстан Республикасы<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» июль 2021 ел №114

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты тарафыннан 2016нчы елның 16нчы декабрендә 151 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016нчы елның 27нче сентябрендәге №668/пр боерыгы белән расланган “Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында“ 2017нче елның 19нчы июнендәге 892/пр номерлы боерыгын кабул итү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының 16.12.2016 №151 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы Нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка - 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндүге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- өч һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен – 0,15;
- пенсионерлар өчен (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар) – 0,15;
- инвалидлар өчен – 0,15.».

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең рәсми стендларында бастырып чыгарырга.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов